| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.09.2021 г .Казань № 244/2-пр

2021 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын
уздыру турындагы нигезләмәне
раслау хакында

Комбайнчы һөнәренең абруен күтәрү һәм аны популярлаштыру, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексында булган урып-җыю техникасы паркыннан нәтиҗәле файдалану һәм 2021 елгы урып-җыю кампаниясендә югары күрсәткечләргә ирешкән комбайнчыларны бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 21 сентябрендәге 1884-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән б о е р а м:

1. «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын уздыру турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Р. Залаковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының
2021 елның 23 сентябрендәге
244/2-пр номерлы боерыгы белән
расланды

2021 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын уздыру турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2021 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсының максатын, аны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. 2021 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсын (алга таба – конкурс) уздыруның максаты - Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елгы урып-җыю кампаниясе барышында ашлык суктыру күләме һәм чаптыру мәйданы буенча югары күрсәткечләргә ирешкән аеруча актив комбайнчыларны бүләкләү.

1.3. Конкурсны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) оештыра.

1.4. Конкурсны уздыру сроклары, шартлары турындагы мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (http://agro.tatarstan.ru) «Белгечләр өчен мәгълүмат» бүлегендә (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) Конкурс турында Министрлык боерыгы үз көченә кергән көннән 3 календарь көн эчендә урнаштырыла.

1.5. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 21 сентябрендәге 1884-р номерлы күрсәтмәсе белән каралган акчалар исәбенә Министрлык тарафыннан башкарыла.

1.6. Конкурсны оештыру һәм уздыру эше түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавамилек һәм ачыклык;

конкурста катнашучыларның тигезлеге.

## 2. Конкурста катнашучылар

2.1. Конкурста катнашуга ашлык җыю комбайннарында, үзйөрешле чапкычларда һәм теземгә салучы ургычларда эшләүче барлык механизаторлар (алга таба - катнашучылар) кертелә.

2.2. Конкурста катнашу өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы барлык авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре 2021 елның 30 сентябренә кадәр Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыралар:

конкурста катнашучыларның гаризаларын карау буенча комиссия утырышы беркетмәсен;

Россия Федерациясе гражданы паспортының күчермәсен;

конкурста катнашучының һәркайсы буенча әлеге Нигезләмәгә кушымтадагы форма буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык.

## 3. Конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен конкурс комиссиясе (алга таба - комиссия) төзелә. Конкурс комиссиясе составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә Министрлыкка кергән документлар комиссия тарафыннан карала.

3.3. Комиссия составына аның рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

3.4. Комиссия рәисе:

комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

3.5. Комиссия секретаре:

комиссия эшчәнлеген оештыра;

комиссия утырышларын уздыру урынын, вакытын билгели;

комиссия утырышының көн тәртибен һәм материалларын әзерли;

комиссия утырышының көн тәртибен раслау өчен комиссия рәисенә кертә;

комиссия утырышлары беркетмәләрен әзерли.

3.6. Комиссия эше утырышлар рәвешендә гамәлгә ашырыла. Комиссия утырышны комиссия рәисе карары буенча уздыра. Комиссия утырышларында комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, утырышлар вәкаләтле санала.

3.7. Комиссия утырышларын комиссия рәисе уздыра, ул булмаган очракта, рәис вазыйфалары аның урынбасарына (алга таба – рәислек итүче) йөкләнә.

3.8. Комиссия әгъзалары аның утырышларында шәхсән үзләре катнашалар.

3.9. Комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

3.10. Комиссия карары утырыш беркетмәсе итеп рәсмиләштерелә. Беркетмә комиссия утырышы узган көннән алып өч эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

3.11. Комиссия утырышы 2021 елның 4 октябреннән дә соңга калмыйча уздырыла.

3.12. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, агросәнәгать комплексы оешмаларыннан һәм аларның вазыйфаи затларыннан комиссия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

бирелә торган мәгълүматның дөреслеген тикшерергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма

органнары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, агросәнәгать комплексы оешмалары җитәкчеләрен, вазыйфаи затларын һәм башка вәкилләрен, шулай ук башка затларны комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен чакырырга.

3.13. Конкурс уздырганда конкурста катнашучының эшчәнлеге түбәндәге күрсәткечләр буенча бәяләнә:

ашлык җыю комбайны – Татарстан Республикасында суктырылган бөртекле, кузаклы һәм техник культураларның максималь күләме буенча;

үзйөрешле чапкычлар һәм теземгә салучы ургычлар–Татарстан Республикасында чаптырылган бөртекле, кузаклы һәм техник культураларның максималь күләме буенча.

3.14. Комиссия 335 кешене конкурста җиңүчеләр һәм призерлар буларак билгели һәм гомуми күләме 10,0 млн. сум булган премияне алар арасында түбәндәге саннарда һәм күләмнәрдә бүлә:

50 мең сум күләмендә 100 премия - (физик затлар өчен салымны (НДФЛ) тотып калып) – ашлык җыю комбайнында бер җиңүчегә;

40 мең сум күләмендә 15 премия - (физик затлар өчен салымны (НДФЛ) тотып калып) – үзйөрешле чапкычларда һәм теземгә салучы ургычларда бер җиңүчегә.

20,0 мең сум күләмендә 220 премия - (физик затлар өчен салымны (НДФЛ) тотып калып) (әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән җиңүчеләрдән тыш) Татарстан Республикасында бөртекле һәм кузаклы культураларны урып-җыюның гомуми мәйданында муниципаль районның чагыштырма күләмен исәпкә алып, Татарстан Республикасы муниципаль районнары арасында бүленә, ул әлеге Нигезләмәнең 3.13 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр буенча бәяләнә.

3.15. Конкурс йомгаклары комиссия утырышы беркетмәсе имзаланган көннән өч эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

3.16. Премияләр Министрлык тарафыннан тапшырыла.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2021 елның 23 сентябрендәге 244/2-пр номерлы боерыгы белән расланган "Иң яхшы комбайнчы" республика конкурсын уздыру турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә

РИЗАЛЫК

Мин, ________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булса)

шәхесне таныклый торган документ __________(документ төре) сериясе _____ № ________, _______________________________________________

бирелгән (кайда, кем тарафыннан һәм кайчан)

теркәлү адресы:
_______________________________________________________________________,

фактта яшәү адресы:

_______________________________________________________________________
Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт адресы буенча теркәлгән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) түбәндәге шартларда үземнең шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирәм:

1. Министрлык минем шәхси белешмәләрне бары тик 2021 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу максатларында гына эшкәртә.

2. Министрлыкка эшкәртүгә тапшырыла торган шәхси белешмәләр исемлеге:

фамилия, исем, ата исеме, туу датасы, паспорт белешмәләре, элемтә телефоны (өй, мобиль, эш), фактта яшәү һәм теркәлү адресы.

3. Үземнең шәхси белешмәләрне Министрлык тарафыннан эшкәртүгә, ягъни түбәндәге гамәлләрне башкаруга ризалык бирәм: шәхси белешмәләрне җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану, шәхеслегемне ачу, блокировкалау, шәхси белешмәләрне юкка чыгару, бу белешмәләрне эшкәртүнең югарыда күрсәтелгән ысулларын гомуми тасвирлау «Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы

Федераль законда китерелгән, шулай ук законнарда билгеләнгән очракларда, мондый мәгълүматны өченче затларга тапшыруга ризалык бирәм.

4. Әлеге ризалык ул имзаланган көннән 5 ел дәвамында гамәлдә була.

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән танышуымны, шәхси белешмәләрне яклау өлкәсендәге хокукларның һәм бурычларның миңа аңлатылуын раслыйм.

20_____ елның «____»______

______________________________________________________________________________

(Имза) (Фамилия, исем, ата исеме – соңгысы - булса)

2021 елда «Иң яхшы комбайнчы»
республика конкурсын уздыру
турындагы Нигезләмәгә
2 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

Тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

Мин, ____________________________________________________________,
(фамилия, исем, ата исеме (соңгысы - булса) рус телендә)

____________________________________________________________,
(почта адресы)

____________________________________________________________,
(электрон почта адресы)

____________________________________________________________,
(телефон номеры)

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә Оештыручыга – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба - Оператор) (ОГРН 1021602854580, ОКТМО 92701000001, ОКПО 00099820), юридик адресы: 420014, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт), 2021 елда «Иң яхшы комбайнчы» республика конкурсында катнашу максатында үземнең шәхси белешмәләрне таратуга (тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган шәхси белешмәләр категорияләре һәм исемлеге

| Т/№ | Шәхси белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | ӘЙЕ | ЮК |
| Гомуми шәхси белешмәләр | | | |
| | Фамилиясе | | |
| | Исеме | | |
| | Атасының исеме (булса) | | |
| | Туу елы, ае, көне һәм урыны | | |
| | Адресы | | |
| | Белеме | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Һөнәре | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгеләнә торган шәхси белешмәләр категорияләре һәм исемлеге

| Т/№ | Шәхси белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Шәхси белешмәләр категориясе] | | |
| | [Шәхси белешмәләр исемлеге] | |

Искәрмә. Әлеге юл шәхси белешмәләр субъекты теләге буенча шәхси белешмәләрне эшкәртүче Оператор ягыннан чикләүләр куелмыйча тутырыла. Шартлар һәм тыюлар шәхси белешмәләрне чикләнмәгән яисә аерым бер даирәдәге затларга Оператор тарафыннан тарату һәм (яисә) бирү гамәлләрен чикләүне яисә тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә шартлар күрсәтелергә мөмкин: алынган шәхси белешмәләр аларны эшкәртүче Оператор тарафыннан аның белешмәләрдән бары тик аерым бер хезмәткәрләр генә файдалана алуны тәэмин итә торган эчке челтәре аша йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, йә алынган шәхси белешмәләрне тапшырмыйча гына таратылырга мөмкин.

Операторның чикләнмәгән даирә файдалана алу мөмкинлеге бирелә торган мәгълүмат ресурслары һәм шәхси белешмәләр субъектының шәхси белешмәләре белән бүтән гамәлләр: https://agro.tatarstan.ru/

Әлеге Ризалыкның гамәлдә булу срогы: ____________________________________________________

(Ризалыкның гамәлдә булуының төгәл срогы)

Шәхси белешмәләр субъекты үзенең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә әлеге Ризалыгын, Операторга язма рәвештә хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Шәхси белешмәләр субъекты тарафыннан үзенең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә әлеге Ризалыгы кире алынган очракта, Оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә мондый эшкәртүне туктатуны тәэмин итәргә (әгәр шәхси белешмәләрне эшкәртү Оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарыла торган булса) тиеш һәм шәхси белешмәләрне эшкәртү максатларында аларны алга таба саклауның кирәге булмаган очракта, Оператор шәхси белешмәләрне юк итәргә яисә аларны юк итүне тәэмин итәргә (әгәр шәхси белешмәләрне эшкәртү Оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарыла торган булса) тиеш, Оператор боларны күрсәтелгән кире алу кергән көннән утыз көннән дә соңга калмыйча башкарырга тиеш. Күрсәтелгән срокта шәхси белешмәләрне юк

итү мөмкинлеге булмаган очракта, Оператор мондый шәхси белешмәләрне блокировкалый (әгәр шәхси белешмәләрне эшкәртү Оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарыла торган булса) һәм шәхси белешмәләрне юк итүне алты айдан да соңга калмыйча тәэмин итә.

______________________ (шәхси белешмәләр субъекты имзасы)
______________________ (көн, ай, ел)